РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ЮТАЗИНСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АБСАЛЯМОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
423957, Республика Татарстан, Ютазинский район, с.Абсалямово, ул. Молодежная д.2
тел./факс: 4-26-79

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ӘБСӘЛӘМ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
423957,Татарстан Республикасы, Ютазы районы, Әбсәләм авылы, Яшьләр урамы, 2
тел./факс: 4-26-79

ПОСТАНОВЛЕНИЕ
№ 3

КАРАР
6 февраль 2023 ел

**Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Әбсәләм авыл җирлеге гражданнарының үзара салым акчаларын җыю тәртибе турында**

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, 2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы Федераль закон, 2004 елның 24 мартындагы «Җирле референдум турында»гы 23-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Әбсәләм авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә,

2022 елның 24 ноябрендәге Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Әбсәләм авыл җирлеге Әбсәләм тимер юл разъезды торак пунктының халык җыенының 1 санлы карары;

2022 елның 24 ноябрендәге Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Әбсәләм авыл җирлегенең Әбсәләм торак пунктында халык җыенының 2 санлы карарларын гамәлгә ашыру максатларында,

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Әбсәләм авыл җирлеге башкарма комитеты к а р а р б и р ә:

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Әбсәләм авыл җирлегендә гражданнарның үзара салымын җыю тәртибен расларга.
2. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга (http:pravo.tatarstan.ru).
3. Әлеге карарның үтәлешен үз контролемдә тотам.

Әбсәләм авыл җирлеге башлыгы Г.В. Кубашева

Әбсәләм авыл җирлеге Башкарма комитетының 2023 елның 6 февралендәге 3 санлы карарына
1 кушымта

**Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Әбсәләм авыл җирлеге гражданнарының үзара салым акчаларын җыю тәртибе**

1. Әлеге тәртип Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Әбсәләм авыл җирлеге гражданнарының үзара салым акчаларын җыю кагыйдәләрен билгели.

2. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Әбсәләм авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән 18 яше тулган гражданнар, Бөек Ватан сугышында катнашучылар һәм аларның тол калган тормыш иптәшләре, хәрби хезмәттә булучылардан тыш, гражданнар җыенында катнашу-катнашмауларына һәм тавыш бирүдә алар тарафыннан белдерелгән мөнәсәбәтләренә бәйсез рәвештә, 2023 елның 1 гыйнварыннан 2023 елның 25 мартына кадәр үзара салым акчалары түләүне башкарыла.

3. Җитди сәбәпләр булган очракта, ә аларга түбәндәгеләр керә ала:

а) торган урын буенча озак яшәмәү,

б) авыру,

гражданнарга гариза нигезендә түләү кертүне өч айдан да артмаган вакытка кичектерергә мөмкин.

4. Бер тапкыр түләү турында хәбәрнамә (искәртү) бланкы гражданнарга мәгълүмат стендларында бастырып чыгару һәм Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында халыкка хәбәр итү юлы белән, шулай ук имзаны тапшыру яисә почта элемтәсе аша юллау юлы белән җиткерелә.

Хәбәрнамәдә (искәртүдә) гражданнарның үзара салым акчаларын күчерүнең түләү реквизитлары, бер тапкыр бирелә торган түләү суммасы, аны түләү вакыты булырга тиеш.

5. Гражданнарның үзара салымыннан алынган акчалар Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Әбсәләм авыл җирлегенең шәхси счетына керә.

6. Түләүләр физик затлар йөкләмәсе буенча исәп-хисап ясау хокукына ия булган оешмалар аша почта күчермәләрен (исәп-хисап оешмалары) гамәлгә ашыру юлы белән башкарыла.

7. Түләү фактын раслый торган касса ордерының квитанциясе, чек-ордер, түләү фактын раслаучы башка документлар.

8. Билгеләнгән вакытка кертелмәгән гражданнарның үзара салымы акчалары законнарда билгеләнгән тәртиптә түләттерелә.

Әбсәләм авыл җирлеге Башкарма
комитетының 2023 елның 6 февралендәге 3
санлы карарына
3 кушымта

Әбсәләм авыл җирлеге бюджетына
үзара салым буенча бер тапкыр түләү турында
____ санлы
ХӘБӘРНАМӘ (ИСКӘРТҮ)

Түләүченең Ф.И.А. ________________________________________________________
Адрес: _____________________________________________________________________
Халык җыены карары нигезендә торак пунктта______________________Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Әбсәләм авыл җирлеге 2023 елда гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча сезгә __________ _ _ _ _ кадәр халык җыены чараларын тормышка ашыру өчен бер тапкыр түләүне түбәндәге реквизитлар буенча башкарырга кирәк:

Банк получателя
БИК

Алучы
Счет номеры №
ИНН КПП
КБК
ОКТМО 92654440
Билгеләнгән түләү 2023 ел өчен Әбсәләм авыл җирлеге гражданнарының үзара салым акчасы.

Җитәкче ______________________________________________________________
П.У. (имза) (имзаны раслау)

- - - - - - - - - - - - - - - - - - кисү линиясе - - - - - - - - - - - - - - -

Әбсәләм авыл җирлеге бюджетына үзара салым буенча бер тапкыр түләү турында
№ ___________________ санлы хәбәрнамә (искәртү)
(муниципаль берәмлек исеме)
__________________ сум күләмендә
Түләүченең Ф.И.А. ________________________________________________________
Адрес: _____________________________________________________________________
«__» _________________ 20__ елны ____________________________________ алдым
(түләүченең имзасы)

*Искәрмә. Мәгълүмат түләүчегә шәхси тапшырылган очракта, аерым корешок тутырыла һәм Әбсәләм авыл җирлеге Башкарма комитетында кала.*